# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"27" ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 27 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2020 елның 27 ноябрендә 19 сәгать 30 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Мирная урамында газүткәргечнең электр-химик яклау КИПын(контроль-үлчәү пунктын) урам уртасыннан урам читенә күчерү - проектын төзү, КИП күчерү буенча монтаж эшләре һәм хезмәт өчен түләү;

2) Асфальт катламын ремонтлау:

- Киров урамындагы 58 - нче номерлы йорттан 34-нче номерлы йортка кадәр асфальт юлдагы чокырларны ремонтлау, материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;

3) Коеларны төзекләндерү :

- Яшьләр урамындагы 28нче һәм 51-нче номерлы йортлар янындагы коеларны ремонтлау, койма белән әйләндереп алу очен төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;

4) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

5) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту.

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенының беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 309 (өч йөз тугыз ) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 172 (бер йөз җитмеш ике) кеше, бу 55,66 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 172 (бер йөз җитмеш ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Тубән Шашы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Тубэн Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Мирная урамында газүткәргечнең электр-химик яклау КИПын(контроль-үлчәү пунктын) урам уртасыннан урам читенә күчерү - проектын төзү, КИП күчерү буенча монтаж эшләре һәм хезмәт өчен түләү;

2) Асфальт катламын ремонтлау:
- Киров урамындагы 58 - нче номерлы йорттан 34-нче номерлы йортка кадәр асфальт юлдагы чокырларны ремонтлау, материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;
3) Коеларны төзекләндерү :
- Яшьләр урамындагы 28нче һәм 51-нче номерлы йортлар янындагы коеларны ремонтлау, койма белән әйләндереп алу очен төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
4) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:
-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;
5) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту.
- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.
мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Салахов И.И.